# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Иске Иркәнәш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**21.11.2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 21.11.2022 елда үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча йомгак беркетмәсе төзелде «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзсалым кертергә ризамы,1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (ком-гравий катнашмасын сатып алу, ташу һәм салу, килешү буенча эшләр өчен түләү): 1 Май урамыннан (тулысынча) Совет урамына кадәр (тулысынча), Совет урамыннан Иске Иркәнәш торак пунктындагы обелискка кадәр.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 178 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 95 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 95 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пункты җирлегендә халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзсалым кертергә,1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан

тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (ком-гравий катнашмасын сатып алу, ташу һәм салу, килешү буенча эшләр өчен түләү): 1 Май урамыннан (тулысынча) Совет урамына кадәр (тулысынча), Совет урамыннан Иске Иркәнәш торак пунктындагы обелискка кадәр.

3. Җыенның нәтиҗәләрен Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) ун көн дәверендә кабул ителгән көннән соң.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы
Минзәлә муниципаль районы

(имза)

Камалов И. З.